| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Кудашевского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кодаш авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.11.2021 Кодаш авылы № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кодаш авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге башлыгы к а р а р  и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кодаш торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2022 елның 16 нояберенэ 13 сәг 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кодаш торак пункты территориясендә,көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш,  яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Бөек Ватан сугышында катнашкан якташлар һәйкәлен реконструкцияләү.

2.Кодаш авылының зират коймаларын яңарту.

3.Кодаш авылында суүткәргечне ремонтлау, су башнясы өчен тирәнлек насослары сатып алу, хезмәт күрсәтү.

4.Янгын сүндерү машинасын карап тоту, янгын сүндерү машинасын йөртүчегә хезмәт килешүе буенча түләү.

5.Урамнарны кардан чистарту, дизель ягулыгы алу һәм тракторчыга килешү буенча хезмәт хакы түләү.

6.МТЗ-82 тракторы өчен асылмалы җиһаз лар сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Кодаш авылы, Тукай урамы, йорт номеры 54, авыл клубында үткәрергә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Ф.М. ШАКИРОВ

АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Совет Кудашевского сельского поселения
Кодаш авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002501
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ